РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**11.12.2025** Кукмара ш. **№ 679**

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 614 номерлы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм:**

1. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 614 номерлы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең карарына, (Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 21 октябрендәге 555 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада: «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып», сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 нче кушымтада:

3.3.2.1 пунктының 11 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган соратуны формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, гариза бирүче тарафыннан соратуның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал тарафыннан соратуның электрон формасындагы дөрес тутырылмаган кыр ачыкланганда, гариза бирүчегә

ачыкланган хатаның характеры һәм аны турыдан-туры соратуның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр ителәә.»;

3) 3 нче кушымтада:

а) 2.8.2.1 пунктының 3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге җир кишәрлеге коммерциягә карамаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән, әлеге ширкәт әгъзасының (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык яисә яшелчә бакчасы булса) яисә бакчачылык яисә коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәтендә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган, федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җир кишәрлеген беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алуга йә Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга хокуклы граждан (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылыкныкы булса) мондый гариза белән мөрәҗәгать итү очракларыннан тыш, шулай ук шулай ук гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып барган территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булса;»;

б) 2.8.2.1 пунктының 8-10 нчы пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8)җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән яисә әлеге карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, җир кишәрлеген бирү турында гариза белән мондый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, андагы бүлмәләр, тәмамланмаган төзелеш объекты милекчесе яисә мондый җир кишәрлегенең хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;

9) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән яисә әлеге карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән, мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге

объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;

10) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән йә, күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән территория чикләрендә урнашкан, җир кишәрлеген арендага бирү турында гариза белән территорияне комплекслы үстерү турында әлеге затның күрсәтелгән объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тота торган шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;»;

а) 2.8.2.1 пунктының 13 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак төзелеше, торак пунктлар чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәр урнаштырылган;»;

г) 2.8.2.1 пунктының 16 нчы пунктчасында «чик» сүзен төшереп калдырырга;

д) 3.3.2.1 пунктының 11 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган соратуны формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, гариза бирүче тарафыннан соратуның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал тарафыннан соратуның электрон формасындагы дөрес тутырылмаган кыр ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны турыдан-туры соратуның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

4) 4 нче кушымтада:

3.3.2.1 пунктының 11 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган соратуны формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, гариза бирүче

тарафыннан соратуның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал тарафыннан соратуның электрон формасындагы дөрес тутырылмаган кыр ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны турыдан-туры соратуның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

5) 5 нче кушымтада:

а) 3.3.2.1 пунктының 11 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган соратуны формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, гариза бирүче тарафыннан соратуның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал тарафыннан соратуның электрон формасындагы дөрес тутырылмаган кыр ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны турыдан-туры соратуның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

б) 1 нче кушымтаның 16 пунктына «бу күчемсез мөлкәт объектлары бирелде» сүзләрен «дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге биналар, корылмалар арендага бирелде», сүзләренә алмаштырырга;

6) 6 нчы кушымтада:

а) 1.5 пунктының 8 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәртип – автомобиль юллары буйлап авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү тәртибе, шул исәптән махсус рөхсәтнең гамәлдә булу срогын,шул исәптән махсус рөхсәтнең гамәлдә булу срогын, авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте маршруты яисә маршруты участогы өчен юл хәрәкәтен оештыру проектын (алга таба – юл хәрәкәтен оештыру проекты), автомобиль юлы яисә аның участогы буйлап транспорт чарасын җибәрү пункты һәм билгеләнгән бару пункты арасында хәрәкәт итү мөмкинлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген килештерү тәртибен (алга таба-юл хәрәкәтен оештыру проекты) үз эченә алган, шулай ук автомобиль юлы хуҗасының автомобиль юлы яисә аның участогы буйлап транспорт чарасында җибәрү пункты һәм билгеләнгән бару пункты арасында гариза бирүченең хәрәкәт итү мөмкинлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны үтәвен раслау тәртибе.»;

б) 2.5.1 пунктының 4 һәм 5 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) һәр транспорт чарасы документларының күчермәләре (транспорт чарасы паспорты яисә транспорт чарасын теркәү турында таныклык, үзйөрешле машина паспорты) - үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеге органнары тарафыннан теркәлгән, шулай ук Россия Федерациясеннән читтә теркәлгән транспорт чаралары өчен;

5) йөк урнаштыруны сурәтләгән (йөк булганда) авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы (автопоезд) схемасы (транспорт чаралары һәм йөк турындагы белешмәләр нигезендә махсус рөхсәт бирү системасы яисә Бердәм порталда автомат рәвештә төзелә, транспорт чаралары автопоездда параллель урнашкан очракта схема гариза бирүче тарафыннан кушып бирелә) әлеге Регламентка 4 нче кушымта нигезендә. Схемада ташуда катнашырга планлаштырыла торган транспорт чарасы, аның йөк һәм беркетү элементлары белән габаритлары (йөк булганда), күчәрләре һәм андагы тәгәрмәчләр саны, күчәрләр һәм тәгәрмәчләрнең үзара урнашуы, күчәрләргә йөкне бүлү, шулай ук йөк булганда – йөк габаритлары, йөкнең транспорт чарасында урнашуы, төяү биеклеге, асылма (булганда) күрсәтелә (яннан, арттан кыяфәте күрсәтелә);»;

в) 3.3.2.1 пунктының 11 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган соратуны формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, гариза бирүче тарафыннан соратуның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал тарафыннан соратуның электрон формасындагы дөрес тутырылмаган кыр ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны турыдан-туры соратуның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**